«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_____И.Г. Һадиуллин
«___» _____ 2026 нчы ел

Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен 2027 елда «Туган (татар) тел» фәненнән бердәм республика имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә варианты

Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2027 году единого республиканского экзамена по учебному предмету «Родной (татарский) язык» для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтиханны башкаруга 3 сәгать 30 минут (210 минут) вакыт бирелә. Ул вакыт эчендә укучылар 3 өлештән торган эшне башкарып чыгарга тиеш.

Беренче өлеш 15 биремне (1-15) үз эченә ала. Һәр биремгә тәкъдим ителгән 4 вариант җавапның берсен, ягъни дөресен генә сайлап алырга кирәк.

Икенче өлеш кыска җавапны таләп иткән 6 биремнән (16-21) гыйбарәт. Бу биремнәргә җаваплары мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга кирәк.

Өченче өлеш бер биремнән (22) гыйбарәт һәм текстка бәйле зур булмаган язма эшне (иншаны) тәшкил итә.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәргә киңәш итәбез. Аларны үтәү барышында кыенлык тудырганы очраса, әлеге биремне калдырып торып, алдагысына күчегез. Вакыт калган очракта, сез бу биремнәргә кабат әйләнеп кайта аласыз.

Дөрес җавап, катлаулылыгыннан чыгып, 1 яки югарырак балл белән бәяләнә. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Уңышлар телибез!

1 нче өлеш

1-15 нче биремнәрнең җавабы сан белән күрсәтелә. Җаваплары 1 нче номерлы җавап бланкына, кирәкле бирем номерыннан уң якка, беренче шакмактан башлап язып куярга кирәк.

1. Сүзнең әдәби әйтелеш нормасын билгеләгез.
1) [йөзэнэң]
2) [йөзөнэң]
3) [йөзөнөң]
4) [йөзэнэн]

2. Алынма сүзне билгеләгез.
1) шкаф
2) иген
3) яфрак
4) болыт

3. Синоним сүзләрне билгеләгез.
1) ашамлык, ризык
2) куе, сыек
3) яңа гына, яңагына
4) авыр, сабыр

4. Тамыр сүзне билгеләгез.
1) төлкедәй
2) укчы
3) күзлек
4) учак

5. *Лицемерить* сүзенең татарчага дөрес тәрҗемәсен билгеләгез.
1) йөзне үзгәртү
2) икейөзлеләнү
3) дөресен сөйләү
4) битне үлчәү

Текстны укыгыз һәм 6 – 11 нче биремнәрне үтәгез.

1) Татарларның ... бабалары Көнчыгыш Европага беренчеләрдән булып акча йөреше керткәннәр. 2) Иң беренче тәңкәләр Идел буенда урнашкан Итил шәһәрендә 737 елда сугыла башлаган. 3) Идел буе шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр, кулланылышта булган гарәп дирһәмнәре белән аралашып, борынгы рус шәһәрләренә үткәннәр. 4) Тәңкә сүзе рус теленә деньга булып кергән.

5) Әйләнештә алтын-көмеш тәңкәләр түгел, ә бакыр пуллар йөргән. 6) Пул сүзенең килеп чыгышы кызыклы: борынгы Римда бакыр акчаның бәясе төшкәч, аларны капчык белән йөрткәннәр (фоллис – капчык). 7) Болгарларга ул пул булып кергән. 8) Бакыр акчаларга төрле-төрле орнаментлар, рәсемнәр төшерелгән була. 9) Аларны, халык яратып алсын өчен, шулай эшләгәннәр.

(Ә. Мөхәммәдиев буенча)

6. 1 нче җөмләдә күп нокталар урынына текст эчтәлегенә туры килгән сүзне билгеләгез.
1) иске
2) борынгы
3) борыннан калган
4) искергән

7. 2 нче җөмләдә аерып бирелгән фигыльнең заманын билгеләгез.
1) үткән заман
2) хәзерге заман
3) киләчәк заман
4) бу фигыль заман белән төрләнмәгән

8. 8 нче җөмләдә кулланылган *орнаментлар* сүзенең мәгънәсен билгеләгез.
1) буяулар
2) бизәкләр
3) сурәтләр
4) чәчәкләр

9. 7-9 нчы җөмләләрдән сүзләрнең туры тәртибе бозылган җөмләне билгеләгез.
1) 7
2) 8
3) 9
4) күрсәтелгән җөмләләрдә сүзләрнең туры тәртибе саклана

10. 3 нче җөмләдәге *белән* бәрәмлегенең сүз төркемен билгеләгез.
1) бәйлек
2) исем
3) рәвеш
4) сыйфат

11. Кайсы очракта күп нокталар урынына *ң* хәрефе языла?
1) ты...лык
2) ты…лый
3) боры…гы
4) күре…де

12. *Иҗат ул <...> рәссамның шәхес буларак камилләшү процессы.(Ф. Суюров)* җөмләсендә күп нокталар урынына куелырга тиеш тыныш билгесен билгеләгез.
1) сызык куела
2) өтер куела
3) ике нокта куела
4) тыныш билгесе куелмый

13. Аерып бирелгән сүзнең кайсы җөмлә кисәге булуын билгеләгез.
Уткер *сүз – уй бинасы. (Г. Афзал)*
1) ия
2) тәмамлык
3) хәл
4) аергыч

Текстны укыгыз һәм 14 - 15, 16 – 21 нче биремнәрне эшләгез.

1) Октябрь башлары...

(2) Кичәге яңгырның болытлары һаман авыл өстендә. (3) Дымлы, караңгы көн, яланаяк басып булмаслык салкын җир өсте, яфраклары сирәгәйгән агачлар, кояшның сүрән яктысы – барысы бергә җәйнең үтеп киткәненә тагын да ныграк ышандыра. (4) Төньяк-көнбатыштан чыккан җил җәяүле буран кебек түбәннән генә исә бугай. (5) Җил үләннәрне тузгыта, камышлар арасына үтеп керә, сәфәр чыгасы кошларны ашыктыра, ояларын какшата. (6) Үрдәкләр генә ашыкмыйлар, нидер көтәләр.

(7) Авылны чыгып, өч чакрымлап юл үткәч, калын катнаш урман башлана. (8) Ерактан кара кучкыл зәңгәр булып күренеп торгангамы, *аның* исеме Карурман...

(9) Сүзендә тора белә икән Нәгыйм абый, Рөстәмнең мәктәптән кайтканын көтеп торган. (10) Карурманга барырга күптән хыялланып йөри иде Рөстәм. (11) Аучы башы белән шушындый кызыклы ауга иярtеп алып чыккач, дус димичә, кем дисең инде Нәгыйм абыйны?!

(12) Алар, «Сәфәри умарталыгы»н сул якта калдырып, ат юлы белән кереп киттеләр.

(13) – Нәгыйм абый, мылтыгыңны күтәреп барыйм әле бераз гына?

(14) – Патронсыз мылтык — күсәк бит ул. (14) Мә, күтәр инде, алай бик теләгәч.

(15) Агач кәүсәләре туннеле аларны «Үрдәкле күл»гә алып чыкты.

(16) «Үрдәкле күл»...

(17) Аны чикләвек, миләш, балан куаклары белән аралашып үскән биек имән, юкә, карамалар камап алган. (18) Бу күл җиргә уелып кергән зур түгәрәк көзге сыман. (19) Өслегендә, кояш нурларын үзләренә иярtеп, кәрәкәләр сикерешә. (20) Язгы гөрләвекләр күлне тирәнәйтә, ә яңгырлар саегудан саклый. (21) Күл янында син үзеңне хыялый бер дөньяда дип хис итәсең. (22) Рөстәм

монда җае чыккан саен килергә тырыша. (23) Я җир җиләге җыючыларга, я балан, чикләвеккә килүчеләргә иярә. (24) Ә бүген ул күршесе Нәгыйм абый белән. (25) Көз җиттеме, Нәгыйм абый ике көпшәле ау мылтыгын кулына ала. (26) Санап карасаң, аның мылтыгы ничәмә-ничә тапкыр атылгандыр инде бу якларда. (27) Карурман — бай урман бит ул. (28) «Үрдәкле күл» кебек күлләре дә берәү генә түгел.

(29) Аучы этсез йөрми. (30) Актырнак та – хуҗасының аерылмас дусты. (31) Атылган үрдәкләрне ташырга аңа гына куш: җитез башкара, ауга еш йөргәне әллә каян билгеле.

(32) Күлгә санаулы адымнар гына калгач, Рөстәм белән Актырнакны калдырып, Нәгыйм абый үзе китте. (33) Алпамшадай зур гәүдәсе, озын балтырлы итекләре белән салам сынган тавыш та чыгармыйча ничек атлый беләдер ул?! (34) Урыныннан да кузгалмый кебек, ә үзе инде камышлар арасына кереп югалды.

(35) Агачтан агачка бәрелеп, шартлау авазы яңгырады... (36) Рөстәм күл өстенә карады, куркудан тигезле-тигезсез хәрәкәтләр ясап, ике якка ике кыр үрдәге күтәрелде. (37) Тагын шартлау...

(38) Куркынган үрдәкләр ике яклап күлне әйләнеп үттеләр дә, кайдадыр ераклата-ераклата очрашып, бер ноктага әйләнделәр.

(39) Шартлау авазы камышлар арасына кереп югалгач, кинәт кенә тынлык урнашты. (40) Әйтерсең бу тынлык Нәгыйм абыйга, Рөстәмгә, хәтта Актырнакка да уйланыр өчен бирелгән иде.

(41) – Кул калтырый, юкса мылтыгым төзәлгән җан иясенә котылу юк иде. (42) Яшьрәк чагымда мылтыксыз-нисез әсир ала идем мин киек кошларны.

(43) Мактану — җиңелүнең бер төре, диләр. (44) Хәер <...> Рөстәмне уйландырганы монысы түгел. (45) Кайтыр юлның зарыктыргыч бер минутында Нәгыйм абыйсы зарланырга кереште:

– Әзәйде үрдәкләр. (46) Элек, ичмасам, ау дисәң дә ау иде... (47) Нәрсә бүселеп барасың, мә, мылтыкны тотып кайт. (48) Күнегә тор, син бит – аучы буласы кеше.

(49) Рөстәм мылтыкны алмады. (50) Бер уй тынгы бирми иде аңа: бу күл элек «Торна күле» дип аталган, хәзер исә анда торнаның каурые да юк. (51) Инде «Үрдәкле күл» диләр. (52) Тора-бара «Кәрәкәле күл» диярләр. (53) Ә кәрәкәләрен дә тотып бетергәч, «Исемсез күл» булып калырмы икән? *(К. Кәримов буенча)*

14. 5 нче җөмләнең төрен билгеләгез.

1) гади, җәенке, ике составлы җөмлә
2) иярченле кушма җөмлә
3) тезмә кушма җөмлә
4) катнаш кушма җөмлә

15. 6 нчы җөмләдә өтернең ни өчен куелганын билгеләгез.
1) Кереш һәм эндәш сүзләр җөмләдә өтер белән аерылалар.
2) Тиңдәш кисәкләр арасына өтер куела.
3) Тезмә кушма җөмләдәге гади җөмләләр өтер белән аерылалар.
4) Җөмләнең аерымланган кисәкләре (аныклагычлар) өтер белән аерылалар.

2 нче өлеш

Әлеге өлештәге биремнәрне үтәгәндә, үз җавапларыгызны 1 нче номерлы җавап бланкында 16 - 21 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда, буш шакмаклар калдырырга ярамый. Тел терминнарын тулы, дөрес һәм баш килештә язу таләп ителә.

16 – 18 нче биремнәргә җавапларны сүзләр белән языгыз.

16. 8 нче җөмләдә аерып бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый?

17. 12-15 нче җөмләләрдән бәйлекне табып языгыз.

18. 44 нче җөмләдә күп нокталар урынына кайсы тыныш билгесе куела?

19 - 21 нче биремнәргә җавапларны цифр белән күрсәтегез.

19. 31-35 нче җөмләләрдән ирен гармониясенә буйсынган сүз булган җөмләнең санын языгыз.

20. 40-43 нче җөмләләр арасыннан *дикий* сүзенең татарчага тәрҗемәсе булган җөмләнең санын языгыз.

21. 49-51 нче җөмләләр арасыннан бер составлы фигыль җөмләнең санын күрсәтегез.

Барлык җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз.

3 нче өлеш

Әлеге өлешкә җавапны 2 нче номерлы бланкта эшләгез. Башта биремнең номерын күрсәтегез (22), аннан соң инша языгыз.

22. Текст нигезендә сочинение языгыз.

Текст авторы тәкъдим иткән проблемаларның берсен формалаштырыгыз һәм аңлатыгыз (цитаталар китерү белән артык мавыкмагыз).

Автор (хикәяләүче) позициясен формалаштырыгыз. Укылган текст авторының фикерләре белән килешү яки килешмәвегезне языгыз, сәбәбен аңлатыгыз. Үз җавабыгызны, беренче чиратта, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләрегезгә нигезләнеп дәлилләгез (беренче ике дәлил игътибарга алыначак).

Иншаның күләме 150 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка нигезләнмичә язылган эш бәяләнми. Әгәр инша сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Иншаны пөхтә, аңлашылырлык итеп языгыз.

Татар теленнән имтихан эшен бәяләү системасы

1 нче өлеш

1 һәм 2 өлешнең һәр биремендәге дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә. Хата җавап яки җавап булмаса, 0 балл куела.

Номер задания	Правильный ответ	Номер задания	Правильный ответ
1	2	**8**	2
2	1	**9**	4
3	1	**10**	1
4	4	**11**	2
5	2	**12**	1
6	2	**13**	4
7	1	**14**	1
		15	2

2 нче өлеш

Номер задания	Правильный ответ
16	АЛМАШЛЫК
17	БЕЛӘН
18	ӨТЕР
19	33
20	42
21	51

3 нче өлешнең сыйфатламасы

1) Октябрь башлары...

(2) Кичәге яңгырның болытлары һаман авыл өстендә. (3) Дымлы, караңгы көн, яланаяк басып булмаслык салкын җир өсте, яфраклары сирәгәйгән агачлар, кояшның сүрән яктысы – барысы бергә җәйнең үтеп киткәненә тагын да ныграк ышандыра. (4) Төньяк-көнбатыштан чыккан җил җәяүле буран кебек түбәннән генә исә бугай. (5) Җил үләннәрне тузгыта, камышлар арасына үтеп керә, сәфәр чыгасы кошларны ашыктыра, ояларын какшата. (6) Үрдәкләр генә ашыкмыйлар, нидер көтәләр.

(7) Авылны чыгып, өч чакрымлап юл үткәч, калын катнаш урман башлана. (8) Ерактан кара кучкыл зәңгәр булып күренеп торгангамы, *<u>аның</u>* исеме Карурман...

(9) Сүзендә тора белә икән Нәгыйм абый, Рөстәмнең мәктәптән кайтканын көтеп торган. (10) Карурманга барырга күптән хыялланып йөри иде Рөстәм. (11) Аучы башы белән шушындый кызыклы ауга иярtеп алып чыккач, дус димичә, кем дисең инде Нәгыйм абыйны?!

(12) Алар, «Сәфәри умарталыгы»н сул якта калдырып, ат юлы белән кереп киттеләр.

(13) – Нәгыйм абый, мылтыгыңны күтәреп барыйм әле бераз гына?

(14) – Патронсыз мылтык — күсәк бит ул. (14) Мә, күтәр инде, алай бик теләгәч.

(15) Агач кәүсәләре туннеле аларны «Үрдәкле күл»гә алып чыкты.

(16) «Үрдәкле күл»...

(17) Аны чикләвек, миләш, балан куаклары белән аралашып үскән биек имән, юкә, карамалар камап алган. (18) Бу күл җиргә уелып кергән зур түгәрәк көзге сыман. (19) Өслегендә, кояш нурларын үзләренә иярtеп, кәрәкәләр сикерешә. (20) Язгы гөрләвекләр күлне тирәнәйтә, ә яңгырлар саегудан саклый. (21) Күл янында син үзеңне хыялый бер дөньяда дип хис итәсең. (22) Рөстәм монда җае чыккан саен килергә тырыша. (23) Я җир җиләге җыючыларга, я балан, чикләвеккә килүчеләргә иярә. (24) Ә бүген ул күршесе Нәгыйм абый белән. (25) Көз җиттеме, Нәгыйм абый ике көпшәле ау мылтыгын кулына ала. (26) Санап карасаң, аның мылтыгы ничәмә-ничә тапкыр атылгандыр инде бу якларда. (27) Карурман — бай урман бит ул. (28) «Үрдәкле күл» кебек күлләре дә берәү генә түгел.

(29) Аучы этсез йөрми. (30) Актырнак та – хуҗасының аерылмас дусты. (31) Атылган үрдәкләрне ташырга аңа гына куш: җитез башкара, ауга еш йөргәне әллә каян билгеле.

(32) Күлгә санаулы адымнар гына калгач, Рөстәм белән Актырнакны калдырып, Нәгыйм абый үзе китте. (33) Алпамшадай зур гәүдәсе, озын балтырлы итекләре белән салам сынган тавыш та чыгармыйча ничек атлый беләдер ул?! (34) Урыныннан да кузгалмый кебек, ә үзе инде камышлар арасына кереп югалды.

(35) Агачтан агачка бәрелеп, шартлау авазы яңгырады... (36) Рөстәм күл өстенә карады, куркудан тигезле-тигезсез хәрәкәтләр ясап, ике якка ике кыр үрдәге күтәрелде. (37) Тагын шартлау...

(38) Куркынган үрдәкләр ике яклап күлне әйләнеп үттеләр дә, кайдадыр ераkта-ераkта очрашып, бер ноктага әйләнделәр.

(39) Шартлау авазы камышлар арасына кереп югалгач, кинәт кенә тынлык урнашты. (40) Әйтерсең бу тынлык Нәгыйм абыйга, Рөстәмгә, хәтта Актырнакка да уйланыр өчен бирелгән иде.

(41) – Кул калтырый, юкса мылтыгым төзәлгән җан иясенә котылу юк иде. (42) Яшьрәк чагымда мылтыксыз-нисез әсир ала идем мин киек кошларны.

(43) Мактану — җиңелүнең бер төре, диләр. (44) Хәер <...> Рөстәмне уйландырганы монысы түгел. (45) Кайтыр юлның зарыктыргыч бер минутында Нәгыйм абыйсы зарланырга кереште:

– Әзәйде үрдәкләр. (46) Элек, ичмасам, ау дисәң дә ау иде... (47) Нәрсә бүселеп барасың, мә, мылтыкны тотып кайт. (48) Күнегә тор, син бит – аучы буласы кеше.

(49) Рөстәм мылтыкны алмады. (50) Бер уй тынгы бирми иде аңа: бу күл элек «Торна күле» дип аталган, хәзер исә анда торнаның каурые да юк. (51) Инде «Үрдәкле күл» диләр. (52) Тора-бара «Кәрәкәле күл» диярләр. (53) Ә кәрәкәләрен дә тотып бетергәч, «Исемсез күл» булып калырмы икән?

(К. Кәримов буенча)

Текст турында мәгълүмат
Текст Камил Кәримовның "Исемсез күл" хикәясеннән кыскартып алынды.

Төп проблема(лар)	Тәрбия проблемасы Табигатьне саклау проблемасы
Автор позициясе	Балалар дөрес тәрбия алырга тиешләр. Табигатьне саклаганда гына, ул кешеләргә файда китерә ала.

Имтихан эшен бәяләү критерийлары

№	*Бәяләү критерийлары*	Баллар
I	***Иншаның эчтәлеге***	
К1	**Чыганак тексттагы проблемаларны формалаштыру**	
	Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен (теге яки бу формада) дөрес формалаштырган. Проблеманы аңлау яки формалаштыруга бәйле фактик хаталар юк.	1
	Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен дә дөрес формалаштыра алмаган.	0
К2	**Чыганак текстның формалаштырылган проблемасын аңлату**	
	Имтихан бирүче формалаштырган проблема чыганак текстка нигезләнеп аңлатылган. Язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле фактик хаталар юк.	2
	Имтихан бирүче формалаштырган чыганак текст проблемасы аңлатылган, **ләкин** чыганак текстка нигезләнмәгән **яки** язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1 фактик	1

	хата бар.	
	Имтихан бирүче формалаштырган проблема аңлатылмаган, **яки** язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1дән артык фактик хатасы бар, **яки** имтихан бирүче формалаштырмаган башка проблема аңлатылган, **яки** аңлатмалар урынына язмада текстның яки аның өзегенең эчтәлеге генә бирелгән, **яки** аңлатмалар урынына чыганак тексттан күләмле өзек кенә китерелгән.	0
К3	**Чыганак текст авторының позициясен чагылдыру**	
	Имтихан бирүче чыганак текст авторының (хикәяләүченең) аңлатылган проблемага бәйле позициясен дөрес формалаштырган. Чыганак текст авторының позициясен аңлауга бәйле фактик хаталар юк. Автор позициясен аңлауда фактик хаталар юк.	1
	Чыганак текст авторының позициясе имтихан бирүче тарафыннан дөрес формалаштырылмаган, **яки** чыганак текст авторының позициясе формалаштырылмаган.	0
К4	**Имтихан бирүченең проблемага карата үз фикерен дәлилләве**	
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (2 дән ким булмаган дәлил китергән, шуларның берсе матур әдәбиятка, публицистик яки фәнни әдәбиятка карый).	3
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2 дән ким булмаган дәлил китергән), **яки** матур әдәбиятка, публицистик яки фәнни әдәбиятка караган 1 генә дәлил китергән.	2
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып дәлилләгән (1 дәлил китергән).	1

	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы билгеләгән проблема буенча, фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, ләкин дәлилләмәгән, **яки** имтихан бирүче фикере формаль рәвештә генә (мәсәлән, “Мин автор фикере белән риза / риза түгел”) бирелгән, **яки** имтихан бирүче фикере язмада бөтенләй чагылыш тапмаган.	0
II	***Иншаның тел ягы***	
К5	**Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге**	
	Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана: – логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган; – абзацларга бүленештә хаталар юк.	2
	Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана, **ләкин** 1 логик хатасы бар, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар.	1
	Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар, **ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **2** урында хата бар.	0
К6	**Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы**	
	Язмада имтихан бирүченең фикере төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган.	2
	Язмада фикер төгәл, **Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган, **яки** язмада төрле грамматик формалар кулланылган, **ләкин** фикер төгәллеге бозылган.	1
	Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган.	0
III	***Грамоталылык***	
К7	**Орфографик нормаларның үтәлеше**	
	Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар).	3
	Хатасы 2 дән артык түгел.	2
	3-4 хата җибәрелгән	1
	Хаталарының саны 4 тән артык	0

К8	**Пунктуацион нормаларның үтәлеше**	
	Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар).	3
	1-3 хатасы бар.	2
	4-5 хатасы бар.	1
	Хаталарының саны 5 тән артык	0
К9	**Тел нормаларының үтәлеше**	
	Грамматик хаталары юк	2
	1–2 хатасы бар	1
	Хаталарының саны 2 дән артык	0
К10	**Сөйләм нормаларының үтәлеше**	
	Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар	2
	2–3 хатасы бар	1
	Хаталарының саны **3** тән артык	0
К11	**Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше**	
	Этикага кагылышлы хаталары юк	1
	Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк)	0
К12	**Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше**	
	Фактик хаталары юк	1
	Фактик хаталары бар	0
Язма эш өчен максималь балл		**23**

Грамоталылыкны (К7-К10) бәяләгәндә, укучы язмасының күләме исәпкә алына. Таблицада күрсәтелгән бәяләү нормалары күләме 130-250 сүздән торган язмаларны бәяләү өчен тәкъдим ителә.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән кимрәк булса, андый эш 0 балл белән бәяләнә, бирем җтәлмәгән булып санала.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән 130 сүзгә кадәр күләмдә булса, К7-К10 нчы критерийлардагы хаталары киметелә. **Бу критерийлар буенча 2 балл түбәндәге очракларда куела:**

К7 – орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар);

К8 – тыныш билгеләренә кагылышлы хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар).

Бу критерийлар буенча 1 балл түбәндәге очракларда куела:

К7 – хатасы 2 дән артык түгел;

К8 – 1-3 хатасы бар;

К9 – грамматик хаталары юк;

К10 – сөйләмгә кагылышлы хаталары 1 дән артык түгел.

Әгәр укучының язмасы 70 сүздән 130 сүзгә кадәр күләмдә генә булса, К7-К12 критерийлары буенча югары балл бөтенләй куелмый.

Әгәр укучының язмасында автор текстының эчтәлеге генә чагылыш тапса яки автор тексты бернинди аңлатмаларсыз күчереп кенә алынган булса, К1-К12 нче критерийлары буенча бу эш 0 балл белән бәяләнә. Чыганак текстка

нигезләнмичә язылган эш бәяләнми.